Кеше ышанмас сүзне дөрес булса да сөйләмә.

*Җөмләдә ничә гади җөмлә бар?*
*Төре буенча бу нинди җөмлә?*

# Тест

**1.Кайсы җөмлә көттерү паузасы белән бирелгән?**

*а) Кем эшләми шул ашамый;*

*б) Минем теләк шул укуны уңышлы тәмамлау;*

*в) Көн салкын торса уңыш начар булачак.*

**2.Баш җөмлә белән иярчен җөмлә арасында өтер билгесе куелган җөмләне сайла**

*а) Җире аз кешеләр батраклыкка яллана иделәр;*

*б) Кайда берлек бар шунда татулык бар;*

*в)Канаты каерылган кош оча алмас.*

**3. Иярченле ия җөмләдә бәйләүче чаралар парлы мөнәсәбәтле сүз белән килсә, нинди тыныш билгесе куела?**

*а)ике нокта*

*б) өтер*

*в) бернинди дә тыныш билгесе куелмый*

# Пунктуация

# Кагыйдәләр китапчыгы

# Бүлекләр:

1. Кызыл юл(абзац)
2. Нокта
3. Сорау
4. Өндәү
5. Күпнокта
6. Сызык
7. Җәяләр
8. Өтер
9. Ике нокта
10. Нокталы өтер

# Сүз...

**1)“Иң  әүвәл Сүз булды...” дип башлана Тәүрат китабында.2) Барысы да сүздән башлана.3) Ә сүз ул- кешенең дөньяны танып- белү тәҗрибәсен башкаларга җиткерү, аралашу коралы.4) Кешенең акыл- зиһен матурлыгы аның сүзләрендә күренә. 5)Тикмәгә генә халык: «Яхшы сүз- җан азыгы, яман сүз- баш казыгы» ,- димәгән.6) Чыннан да, яхшы сүз кешенең күңелен күтәрә, авырлыкларны җиңәргә көч бирә, батырлыклар эшләргә рухландыра.7) Яман сүз изге хисләрне үтерә, кешенең кулыннан эше төшә,хәтта кешене упкыннар читенә китереп тери.**

**8) Без гомер буе сүзләр белән аралашып яшибез. 9)Сүзләр безне бәхетле дә, бәхетсез дә итә ала... 10) Сүзләр әйтерсең лә кояш: алар һәркемнеке дә, һәммәбезнеке дә. 11) Һәркемнең үз кояшы булган кебек, һәркемнең үз сүзе, үз язмышы…**

*Бирем:* ***В1*** *1-5 нче җөмләләрдән ия белән хәбәр арасында  сызык куелган очрак булган җөмләнең номерын күрсәт.*

***В2***  *5-8 нче җөмләләрдән кереш сүзне аерып яз*

**В3**  *1-8 нче җөмләләрдән тезмә кушма җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә яз*

***В4*** Иярчен тәмамлык җөмләле кушма җөмләне табарга, номерын яз